# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Наратлы-Кичү торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

.

**18 ноябрь 2025 ел** **№ 4**

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичу авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичу авыл җирлегенең Наратлы-Кичу торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичу авыл җирлеге Наратлы-Кичу торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 һәм 2 төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарын, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарын, күп балалы гаиләләрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк булган гражданнарны, Россия Армиясенә чакырылган гражданнарны, СВО зонасында хезмәт итүче гражданнарны һәм аларның гаилә әгъзаларын, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларын искәрмә итеп алырга).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Наратлы Кичү торак пунктында, Мира урамындагы иске зиратта ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү(төзелеш материаллары сатып алу).
2) Наратлы-Кичу торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (яктылык җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Наратлы-Кичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге башлыгы ____________ Вәлиев И.М.
.